РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
МАНЗАРАССКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422110, РТ, Кукморский район, Манзарас,
ул. 1 Мая, д. 57 а
Эл. почта: Man.Kuk@tatar.ru
тел./факс: 8 (84364) 2-91-92

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАНЗАРАС АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, РТ, Кукмара районы, Манзарас авылы,
1Май урамы, 57а йорт
Эл. почта: Man.Kuk@tatar.ru
тел./факс: 8 (84364) 2-91-92

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» февраль 2026 ел № 10

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге территориясендә адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәреш кертү турында 2025 елның 29 сентябрендәге 776 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне гамәлгә ашыру максатларында, Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге территориясендә адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга
(кушымта итеп бирелә)

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 сентябрендәге 91 номерлы

Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитеты карары.

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 23 ноябрендагы 104 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү турында» Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 22 сентябрендәге 92 номерлы карары.

- «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 июнендәге 21 номерлы Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитеты карарының 5 пункты.

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында» Манзарас авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 21 маендагы 47 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Манзарас авыл җирлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы : Хабибуллина Р.Г.

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Манзарас авыл Башкарма комитетының
2026 елның «10» февраленнан
10 номерлы карарына кушымта

**Адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик затлар һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгару турында гариза (алга таба – гариза) адрес бирелә торган объект хуҗасы тарафыннан үз инициативасы буенча яисә адрес бирелә торган объектка карата түбәндәге әйбергә ия булу хокукының берсе булган зат тарафыннан тапшырыла:

а) хуҗалык алып бару хокукы;
б) оператив идарә итү хокукы;
в) гомерлек мирас итеп алу хокукы;
г) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы.

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен гариза бирүченең билгеләнгән тәртиптәге вәкаләтле затлары һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүче вәкиле) тәкъдим итә ала.

Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре исеменнән мондый милекчеләрнең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән әлеге милекчеләрнең гомуми җыелышы карары белән мондый гариза бирүгә вәкаләтле вәкиле гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәте әгъзалары исеменнән мондый ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән мондый гаризаны бирергә вәкаләтле ширкәт вәкиле гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә кадастр эшләре яки адрес бирелә торган объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата комплекслы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Муниципаль хезмәт гариза бирүчегә гариза бирүченең «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы»нда (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы

4. Адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару.

### Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган исеме

5. Муниципаль хезмәтне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы _____________ авыл җирлеге Башкарма комитет күрсәтә.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Гариза бирүче «Адрес бирелә торган объектка адрес бирү, мондый адресны үзгәртү һәм юкка чыгару»ны сорап мөрәҗәгать иткәндә, түбәндәгеләр муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) адрес бирелә торган адрес бирү, үзгәртү яисә юкка чыгару турында карар (5 нче кушымта), Дәүләт адреслар реестрыннан өземтәне кушымта итеп;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (6 нчы кушымта).

Адрес бирелә торган объектның адресын юкка чыгару турында карар, адреслау объектына яңа адрес бирү очрагында, әлеге адрес бирелә торган объектка яңа адрес бирү турында карар белән берләштерелергә мөмкин.

Реестрга белешмәләр кертү «Дәүләт адреслар реестрындагы белешмәләрне дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, физик һәм юридик затларга, шул исәптән федераль мәгълүмат адреслар системасыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү юлы белән бирү тәртибе, ысуллары һәм формалары турында»

2020 елның 14 сентябрендәге 193н номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгына 2 нче кушымта нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә торган дәүләт адреслар реестрыннан тиешле өземтә белән раслана.

7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитетның вазыйфаи затының (яки Башкарма комитетның) көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ рәвешендә Бердәм портал, Республика порталы яисә Адреслы система порталында шәхси кабинетына җибәрелә.

8. Шулай ук, гариза бирүче сайлавы буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүче түбәндәгечә алырга мөмкин:

- Башкарма комитетта кәгазьдә бастырылган электрон документ рәвешендә;

- КФҮдә Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә.

9. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның кәгазь чыганактагы нөсхәсен муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты

10. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

а) кәгазьдә гариза биргән очракта – гариза кергән көннән алып күп дигәндә 10 эш көнендә;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта – гариза килгән көннән алып күп дигәндә 5 эш көнендә.

11. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

12. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

**Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге**

13. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

1) Регламентка 3 нче кушымта нигезендә гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә бирелергә тиешле документларны тапшырмау яисә каршылыклы белешмәләр булган документлар тапшыру;

2) законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган белешмәләрне расламау, гариза бирүче исеменнән моңа вәкаләтле булмаган зат тарафыннан гариза (сорату) бирелүе;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәле, килешенмәгән төзәтмәләр, җитди бозулар булган документлар, үз көчен югалткан документлар тапшыру;

5) Регламентка 3 нче кушымта нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булмаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (тутырылмаган булу, әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган, дөрес булмаган, тулы булмаган йә дөрес булмаган), гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

7) электрон формадагы гариза (сорату) һәм башка документлар, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган.

14. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге нигезләр буенча кабул ителә:

1) ведомствоара соратуга җавап адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгару өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын раслый, һәм тиешле документ гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган;

2) гариза бирүче инициативасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны кире алу;

3) гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгару өчен гариза бирү вазыйфасын йөкли торган документлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән;

4) адрес бирелә торган объектка Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләренең 5, 8 – 11 һәм 14 – 18 пунктларында күрсәтелгән адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару очраклары һәм шартлары юк.

16. Гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр,

гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

18. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.
19. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү вакыты

20. Гариза биргән көнне КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмати системасыннан гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры белән гариза бирү датасы күрсәтелгән расписка бирелә.
21. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы яки Адреслар системасы порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталында шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры белән электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.
22. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, ике нөсхәдә гариза бирелгән көнне Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты, гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп, гариза бирүчегә бер нөсхәсен кире кайтара.

Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

23. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.
Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.
24. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:
1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (бинага уңайлы керү/бинадан уңайлы чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү);
2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла;
3) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;
4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска кулланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;
5) инвалидларның хезмәт күрсәтү урыннарына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;
6) инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;
7) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертү;
8) йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда кертергә рөхсәт итү.
25. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм Регламентның 24 пунктының 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.
26. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

Мунципаль хезмәтнең һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре

27. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документлар кабул итү, бирү урынының җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең житәрлек санда булуы;

мәгълүмати стендларда, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

1) документларны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) муниципаль хезмәттән файдаланганда, гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документның нөсхәсе рәвешендә КФҮдә алу кирәк булган очракта, бер тапкыр.

Хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вәкаләтле затлар белән бер хезмәттәшлеге дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары, Бердәм портал, Республика порталы, терминаль җайланмалар ярдәмендә бәяләргә хокуклы.

29. Хезмәт күрсәтүнең гариза бирүчеләрнең ихтыяҗларына туры килүенә тикшерү кире элемтәне анализлау нигезендә даими үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү гариза бирүчеләрнең хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе тотрыклы кимегән очракта (рәттән өч айдан артык) башкарыла.

Хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимальләштерү кимендә биш елга бер мәртәбә үткәрелә.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы һәм статусы турында мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетында, КФҮдә алырга мөмкин.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтү гариза бирүченең яшәү урынына яисә экстерриториаль принцип буенча фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, аның сайлавы буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

32. Гариза бирүче муниципаль хезмәтне комплекслы сорату составында алырга хокуклы.

33. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

34. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә танылканган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып бирергә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларны үтәү барышы һәм статусы турында мәгълүматлар алырга;

г) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

35. Гаризаны формалаштыру Бердәм порталда, Республика порталында нинди дә булса башка формада гариза бирү зарурлыгыннан башка гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

36. Гариза бирүчеләрнең КФҮгә кабул итү өчен язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮнең элемтә үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә кабул итү өчен теләсә нинди буш датага һәм вакытка күпфункцияле үзәкнең кабул итү

графигында билгеләнгән чикләрдә язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу бу датага кадәр бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүче система сората торган мәгълүматларны күрсәтергә тиеш, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

теләгән дата һәм кабул итү вакыты.

Гариза бирүче алдан язылганда хәбәр иткән мәгълүматларның шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тапшырган документларга туры килмәве очрагында, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылганда, гариза бирүчегә талон-раслауны чыгартып алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, шулай ук күрсәтелгән адреска, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда, гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә, кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан соң 15 минут узгач килмәгән очракта, алдан язылуның юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче алдан язылудан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, кабул итүнең максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр бирүдән тыш, гариза бирүчедән башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

37. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленештә:

а) гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар;

б) гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен үзе тапшырырга хокуклы документлар.

38. Гариза формалары һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турында белешмәләр әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## III. Административ процедуралар үтәлешенең составы, эзлеклелеге һәм вакыты

Административ процедуралар исемлеге

39. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

40. Муниципаль хезмәт алу өчен «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати соратулар җибәрергә кирәк:

1) «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (күчемсез мөлкәт объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында белешмәләр)» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә» җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратыла торган белешмәләрне ведомствоара сорату җибәрелгән вакыттан алып 1 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

2) «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Федераль салым хезмәтенә» җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратыла торган белешмәләрне ведомствоара сорату җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра; Сорату хезмәт күрсәтүне сорап юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Федераль салым хезмәтенә» җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратыла торган белешмәләрне ведомствоара сорату җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра; Сорату хезмәт күрсәтүне сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

41. Муниципаль хезмәт алу өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати сратулар җибәрергә кирәк:

1) «Гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату, гариза бирүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, «Граждан хәле актларын яздыруның Бердәм дәүләт реестры» сервисы йә «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы аша 1 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) «Ышанычнамәне бирү факты һәм аның эчтәлеге турында белешмәләр» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорау «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы аша 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

3) «Адрес бирелә торган объектның тиешле территориянең кадастр планында яисә кадастр картасында урнашу схемасы» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

4) «Адрес бирелә торган объектны төзүгә рөхсәт (төзелә торган адрес бирелә торган объектларга адрес бирү өчен) һәм (яки) адрес бирелә торган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт (тапшырылган адрес объектларына адрес бирү өчен)» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

5) «Торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турында жирле үзидарә органы карары» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

6) «Бер һәм аннан да күбрәк яңа адрес бирелә торган объектлары барлыкка килүгә китерә торган бинаны үзгәртеп төзү һәм (яисә) яңадан планлаштыру уздырганда, кабул итү комиссиясенең тәмамланган үзгәртеп төзү (яңадан планлаштыру) турында акты (бер һәм аннан да күбрәк яңа адрес бирелә торган объектларны барлыкка китереп, адрес бирелә торган объектларны (биналарны) үзгәрткән очракта)» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

7) «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлергә тиеш булмаган муниципаль мөлкәтне, жир кишәрлеген бирүгә шартнамә турында белешмәләр» мәгълүмати соратуы. Күрсәтелгән мәгълүмати сорату Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 2 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына .

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

42. Техник мөмкинлеге булганда, гариза бирүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтүгә аның соратуының статусы үзгәрүе (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында башкарырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән ысулларның берсе аша хәбәр ителә:

- смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
- Бердәм портал аша;
- Республика порталы аша;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

1 нче кушымта

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2. Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (https:/www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);
3. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең федераль реестры» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4. Кукмара муниципаль районы __________ авыл жирлеге башкарма комитеты – Башкарма комитет;
5. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.
6. Федераль мәгълүмати адреслар системасы (https://fias.nalog.ru/) – адреслар системасы порталы.

2 нче кушымта

**Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе исеме | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки гамәлдән чыгару турында карар | Адрес бирелә торган объектның милекчесе булган физик зат | 1А |
| 2. | | Адрес бирелә торган объектның милекчесе булган юридик зат | 2А |
| 3. | | Адрес бирелә торган объектның милекчесе булган шәхси эшмәкәр | 3А |
| 4. | | Хуҗалык алып бару хокукында адрес бирелә торган объектка ия физик зат | 4А |
| 5. | | Хуҗалык алып бару хокукында адрес бирелә торган объектка ия юридик зат | 5А |
| 6. | | Хуҗалык алып бару хокукында адрес бирелә торган объектка ия шәхси эшмәкәр | 6А |
| 7. | | Оператив идарә итү хокукында адрес бирелә торган объектка ия физик зат | 7А |
| 8. | | Оператив идарә итү хокукында адрес бирелә торган объектка ия юридик зат | 8А |
| 9. | | Оператив идарә итү хокукында адрес бирелә торган объектка ия шәхси эшмәкәр | 9А |
| 10. | | Гомерлеккә мирас итеп бирелә торган биләмә хокукында адрес бирелә торган объектка ия физик зат | 10А |
| 11. | | Гомерлеккә мирас итеп бирелә торган биләмә хокукында адрес бирелә торган объектка ия юридик зат | 11А |
| 12. | | Гомерлеккә мирас итеп бирелә торган биләмә хокукында адрес бирелә торган объектка ия шәхси эшмәкәр | 12А |
| 13. | | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында адрес бирелә торган объектка ия физик зат | 13А |
| 14. | | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында адрес бирелә торган объектка ия юридик зат | 14А |
| 15. | | Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында адрес бирелә торган объектка ия шәхси эшмәкәр | 15А |
| 16. | | Гариза белән 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган документ нигезендә кадастр эшләре яки адрес бирелә торган объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата комплексллы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры | 16А |
| 17. | | Гариза бирүче вәкиле | 17А |

3 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Гариза бирүче тапшыра торган документлар төрләрен расшифровкалау, төркемнән документлар саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| | | *Гариза бирүче, хезмәт күрсәтү өчен, үзе тапшырырга тиешле документлар* | |
| 1. | 1А-17А | Гариза | Бердәм портал, Республика порталы, Адреслар системасы порталы, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-17А | Гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ | Бердәм портал, Республика порталы, Адреслар системасы порталы, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 17А | Гариза бирүче вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ | Адреслар системасы порталы, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 16А | «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясында яки 42.3 статьясында каралган, аның нигезендә адрес бирелә торган объекты булган тиешле күчемсез милек объектына карата кадастр эшләрен яки комплексны кадастр эшләрен башкару гамәлгә ашырыла документ | Бердәм портал, Республика порталы, Адреслар системасы порталы, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |
| | | *Гариза бирүче, Хезмәт күрсәтү өчен, үзе тапшырырга хокуклы документлар* | |
| 1. | 1А-17А | Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында аларга хокуклар теркәлмәгән адрес бирелә торган объектларына хокук билгели торган документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Адреслар системасы порталы, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре 2.0» мобиль кушымтасы, Башкарма комитет, КФҮ |

5 нче кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

**1) адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки гамәлдән чыгару турында карар ФОРМАСЫ**

«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары нигезендә, ______________________________ нигезләнеп
:

(адрес бирү/гамәлдән чыгару нигезләре күрсәтелә)

1. адрес бирелә торган объектка бирергә (гамәлдән чыгарырга) :
______________________________

объект төре, кадастр номерлары, адреслар һәм адрес бирелә торган объект төзелә торган күчемсез милек объектлары турында белешмәләр;

______________________________

кадастр номеры (дәүләт кадастр исәбенә куелган күчемсез милек объектына адрес бирү очрагында)
карарган:

______________________________

ФИО, оешманың исеме

киләсе адрес:
______________________________

объект адресы, адрес бирелә торган объектның гамәлдән чыгарыла торган адресы һәм дәүләт адреслар реестрында адрес бирелә торган объектның гамәлдән чыгарылган адресының уникаль номеры

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны ______________________________ калдырам.

3. Боерык ______________________________ үз көченә керә

Башкарма комитет җитәкчесе ____________

6 нчы кушымта

(Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган бланкы)

**Адрес бирелә торган объектка адрес**
**бирү яки аның адресын гамәлдән чыгарудан баш тарту турында карар ФОРМАСЫ**

________________________________________

________________________________________
(гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) Ф.И.А., адресы)

________________________________________
(адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгару турында гаризаның теркәү номеры)

**Адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар**
... _____________ № __________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(җирле үзидарә органы исеме)

турында..............хәбәр итә _____________________________________________________ ,
(Гариза бирүченең Ф.И.А. юнәлеш килешендә, шәхесне раслый торган документның исеме, номеры һәм бирү датасы,

______________________________________________________________________________
почта адресы – физик зат өчен; тулы исеме, ИНН, КПП

______________________________________________________________________________
(Россия юридик заты өчен), ил, теркәлү датасы һәм номеры (чит ил юридик заты өчен),

____________________________________________________________________________ ,
почта адресы – юридик зат өчен)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләре нигезендә, адрес бирелә торган объектка адрес бирү (гамәлдән чыгару) кире кагылды

(кирәклесенең астына сызарга)
____________________________________________________________
(адрес бирелә торган объектның төре һәм атамасы,

______________________________________________________________________________
гариза бирүче адрес бирелә торган объектка адрес бирү турында мөрәҗәгать иткән очракта, адрес бирелә торган объектның урнашу урынын тасвирлау,

______________________________________________________________________________
гариза бирүче адрес бирелә торган объектның адресын гамәлдән чыгару турында мөрәҗәгать иткән очракта, адрес бирелә торган объектның адресы)

______________________________________________________________________________
белән бәйле рәвештә

______________________________________________________________________________
(баш тарту нигезе)

Җирле үзидарә органының вәкаләтле заты

________________________________________ __________________
(вазыйфасы, Ф.И.А.) (имза)

7 нче кушымта

**Адрес бирелә торган объектка адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында ГАРИЗА ФОРМАСЫ**

| | | |
|---|---|---|
| | Бит № ___ | Барлыгы битләр ___ |

<table>
<tr><td>1</td><td>Гариза<br>кемгә...<br>---------------------------------------<br>(җирле үзидарә органы исеме)<br>________________________________</td><td>2</td><td colspan="3">Гариза кабул ителде<br>теркәлү номеры _______________<br>гаризаның битләре саны ___________<br>кушып бирелгән документлар саны ____,<br>шул исәптән төп нөсхәләр ___, күчермәләр ____, төп нөсхәләрдә битләр саны ____,<br>күчермәләрдә битләр саны ____<br>Вазыйфаи затның ФИА ________________<br>вазыйфаи затның имзасы ____________<br>дата «__» ____________, ____ ел</td></tr>
<tr><td rowspan="4">3.1</td><td colspan="5">Адрес бирелә торган объектка карата сорыйм:</td></tr>
<tr><td colspan="5">Төр:</td></tr>
<tr><td></td><td>Җир кишәрлеге</td><td></td><td>Каралты</td><td rowspan="2"></td><td rowspan="2">Машина урыны</td></tr>
<tr><td></td><td>Бина (корылма)</td><td></td><td>Бүлмә (помещение)</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td rowspan="13">3.2</td><td colspan="3">Адрес бирергә</td></tr>
<tr><td colspan="3">Түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2">Дәүләт яисә муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеге (кишәрлекләре) төзү</td></tr>
<tr><td colspan="2">Төзелә торган җир кишәрлекләре саны</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2" rowspan="3">Өстәмә мәгълүмат:</td><td></td></tr>
<tr><td></td></tr>
<tr><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Җир кишәрлеген бүлү юлы белән җир кишәрлеге (кишәрлекләре) төзү</td></tr>
<tr><td colspan="2">Төзелә торган җир кишәрлекләре саны</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="2">Бүлү башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры</td><td>Бүлү башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр адресы</td></tr>
<tr><td colspan="2"></td><td></td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | |
| Җир кишәрлеген берләштерү юлы белән җир кишәрлеге төзү | |
| Берләштерелә торган җир кишәрлекләре саны | |
| Берләштерелә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры <1> | Берләштерелә торган җир кишәрлегенең адресы <1> |
| | |
| | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бит № ___ | Барлыгы битләр ___ |

| | |
|---|---|
| Җир кишәрлегеннән бүлеп алу юлы белән җир кишәрлеге төзү | |
| Төзелә торган җир кишәрлекләре саны (бүлеп алына торган җир кишәрлегеннән тыш) | |
| Аңардан бүлеп бирелә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры | Аңардан бүлеп бирелә торган җир кишәрлегенең адресы |
| | |
| | |
| Җир кишәрлеген кабат бүлү юлы белән җир кишәрлеге (кишәрлекләре) төзү | |
| Төзелә торган җир кишәрлекләре саны | Яңадан бүленә торган җир кишәрлекләре саны |
| | |
| Яңадан бүленә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры <2> | Яңадан бүленә торган җир кишәрлегенең адресы <2> |
| | |
| | |
| Бинаны (корылманы), каралтыларны төзү, реконструкцияләү | |
| Проект документлары нигезендә төзелеш (реконструкция) объектының исеме | |
| Төзелеш (реконструкция) башкарыла торган җир кишәрлегенең кадастр номеры | Төзелеш (реконструкция) башкарыла торган җир кишәрлегенең адресы |
| | |
| | |

| | |
|---|---|
| | Күрсәтелгән адрес бирелә торган объектны дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны киләсе адрес бирелә торган объектка карата әзерләү, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе субъектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә аны төзү, реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителмәгән очракта |

| | |
|---|---|
| Бинаның (корылманың), каралтының тибы | |
| Төзелеш (реконструкция) объектының исеме (проект документлары булганда, проект документларына туры китереп күрсәтелә) | |
| Төзелеш (реконструкция) башкарыла торган жир кишәрлегенең кадастр номеры | Төзелеш (реконструкция) башкарыла торган жир кишәрлегенең адресы |
| | |
| | |

| | |
|---|---|
| | Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү |

| Бүлмәнең (помещение) кадастр номеры | Бүлмәнең (помещение) адресы |
|---|---|
| | |
| | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бит № ___ | Барлыгы битләр ___ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бинада (каралтыда), корылмада бинаны (каралтыны), корылманы бүлү юлы белән бүлмә (бүлмәләр) төзү | | | |
| | | Торак бина төзү | Төзелә торган биналар саны | |
| | | Торак булмаган бина төзү | Төзелә торган биналар саны | |

| Бинаның, корылманың кадастр номеры | Бинаның, корылманың адресы |
|---|---|
| | |
| | |
| Өстәмә мәгълүмат: | |
| | |
| | |

| | |
|---|---|
| | Бинада (каралтыда), корылмада бүлмәне (помещение), машина-урынны бүлү юлы белән бүлмә (бүлмәләр) төзү |

| Бинаның билгеләнеше (торак (торак булмаган) бина) <3> | Бүлмә (помещение) төре <3> | Бүлмәләр саны <3> |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |

| Бүлү башкарыла торган бинаның, машина-урынның кадастр номеры | Бүлү башкарыла торган бинаның, машина урынының адресы |
|---|---|
| | |
| | |
| Өстәмә мәгълүмат: | |
| | |
| | |

| | Бинада (корылмада), каралтыда бинадагы (корылмадагы), каралтыдагы бүлмәләрне, машина-урыннарны кушу юлы белән бүлмә (помещение) төзү | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Торак бина төзү | | Торак булмаган бина төзү |

| Берләштерелә торган бүлмәләр саны | |
|---|---|
| Берләштерелә торган бүлмәнең кадастр номеры <4> | Берләштерелә торган бүлмәнең адресы <4> |
| | |
| | |
| Өстәмә мәгълүмат: | |
| | |
| | |

| | Гомуми файдаланудагы урыннарны үзгәртеп төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру юлы белән бинада, каралтыда бүлмәләр төзү | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Торак бина төзү | | Торак булмаган бина төзү |

| Төзелә торган биналар саны | |
|---|---|
| Бинаның, корылманың кадастр номеры | Бинаның, корылманың адресы |
| | |
| | |
| Өстәмә мәгълүмат: | |
| | |
| | |

| | Бинаны, каралтыны бүлү юлы белән бинада, каралтыда машина-урын төзү |
|---|---|
| Төзелә торган машина урыны саны | |